ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 23 2017 елның 16 гыйнвары

2017 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының азык-төлек иминлеген тәэмин итү һәм туклануын оештыру максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанслар департаментына (Логинова С.Н.) җирле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә каралган акчаларны түбәндәгеләргә үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә:

- уку елы дәвамында бер укучыга бер көнгә 6 сум 80 тиен исәбеннән туклану бәясенең кыйммәтләнүенә өлешчә компенсация;

- озайтылган көн төркемнәрендә түләүсез яки ташламалы туклану (озайтылган көн төркеменә йөрүчеләрнең 17,5 % на кадәр күләмдә).

2. Түбән Кама муниципаль районының социаль яктан яклanmaган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатыннан, 2017 елга гомуми белем бирү оешмаларының расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә туклану түбәндәге категория укучылар өчен ата-аналар кертемнәрен түләүдән азат итәргә:

- ятим балалар һәм опекага алынган балалар;

- инвалид балалар;

- Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан гаилә балалары;

- җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган азкеремле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдәге балалар.

3. Түбән Кама муниципаль районы шәһәр мәктәп-интернатларына Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2007 елның 17 декабрендәге 721 номерлы «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләренә норматив финанслауны кертү турында» карары нигезендә, карап-тәрбияләүгә ата-аналар кертемнәре исәбенә туклану өчен чыгымнарны кайтарырга.

4. 2017 елның 1 гыйнварыннан расларга:

4.1. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларның бер көнгә туклану бәясе:

- 1-4 сыйныфлар өчен 30 сум 70 тиен күләмендә;

- 5-11 сыйныфлар өчен 35 сум 70 тиен күләмендә.

4.2. Барлык типтагы мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләр өчен бер көнгә туклану бәясе мәктәп яшендәге бер тәрбияләнүчегә 134 сум 35 тиен.

4.3. Махсус (коррекцион) гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләр өчен бер көнгә туклану бәясе бер тәрбияләнүчегә 150 сум 63 тиен.

4.4. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2016 елның 21 сентябрендәге 664 номерлы «2017 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» карары нигезендә, уку чорында бер укучыга бер көнгә айлык акчалата түләүләр бәясе 6 сум 80 тиен тәшкил итә.

4.5. Укучылар өчен шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында төшке ашка ата-аналар кертемнәре суммасы:

- 1-4 сыйныфлар 23 сум 90 тиен күләмендә;

- 5-11 сыйныфлар 28 сум 90 тиен күләмендә.

4.6. Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында озайтылган көн төркемендәге ата-аналар кертемнәренең суммасы - 15 сум 00 тиен.

5. Авыл җирлекләрендә һәм Кама Аланы шәһәр тибындагы бистәсендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларына:

5.1. 2017 елга муниципаль бюджет исәбеннән авыл гомуми белем бирү оешмаларында бушлай ашаучылар санын расларга (1 нче кушымта).

5.2. Укучыларны тукландыруны оештыру өчен мәктәп яны участокларында җыелган һәм санитар-гигиена нормаларына туры килә торган уңыштан файдаланырга.

5.3. Укучыларны кайнар аш, витаминнар һәм минераль матдәләр белән баетылган азык-төлек белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү өчен, укучыларны туклануны түбәндәге исәптән оештырырга:

- Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2016 елның 21 сентябрендәге 664 номерлы «2017 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» карары нигезендә, белем алу чорында бер укучыга бер көнгә 6 сум 80 тиен;

- 20 сумга кадәр – төшке ашка ата-аналар кертемнәре;

- 15 сумга кадәр – озынайтылган көн төркемендә ата-аналар кертемнәре.

6. Гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән булган балаларны тукландыруны Нигезләмә нигезендә оештырырга (2 нче кушымта).

7. Түбән Кама муниципаль районы мәгариф оешмаларына, азык-төлек продуктларын сатып алу процедураларын үткәрү нәтиҗәсендә, бюджет акчаларын экономияләүдән барлыкка килгән акчаларны социаль яктан якланмаган гаиләләрдән булган укучыларга, шул исәптән ОКТ гә йөрүче укучыларга өстәмә туклану оештыруга юнәлтергә.

8. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре территориаль бүлегенә (Изиятуллин Р.М.) гомуми белем бирү оешмаларында санитар-гигиена нормаларының үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтергә тәкъдим итәргә.

9. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 29 декабрендәге 1325 номерлы «2016 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү

учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 16 гыйнварындагы
23 номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

2017 елга муниципаль бюджет хисабына
авыл гомуми белем бирү оешмаларында түләүсез ашаучылар саны

| Гомуми белем бирү оешмасы исеме | Муниципаль бюджет хисабына бер көнгә туклану бәясе, шул исәптән | | | **Ташламалы тукланучы укучылар саны** |
|---|---|---|---|---|
| | дотация (6,80руб.) | түләүсез туклану (1,90) | гомуми | |
| Олы Афанас УГББМ | 6,80 | 15,0 | 21,8 | **35** |
| Благодатное УГББМ | 6,80 | 15,0 | 21,8 | **11** |
| Югары Уратма ГББМ | 6,80 | 18,0 | 24,8 | **9** |
| Югары Чаллы УГББМ | 6,80 | 17,0 | 23,8 | **10** |
| Елантау ГББМ | 6,80 | 15,0 | 21,8 | **7** |
| Каенлы УГББМ | 6,80 | 13,0 | 19,8 | **13** |
| Кармалы УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **15** |
| Кызыл Чишмә УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **20** |
| 1 номерлы Кама Аланы УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **39** |
| 2 номерлы Кама Аланы УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **71** |
| Түбән Уратма УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **6** |
| Сухрау УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **11** |
| Иске Чишмә УГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **9** |
| Ширәмәт УГББМ | 6,80 | 15,0 | 21,8 | **12** |
| Шәңгәлче ГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **7** |
| Трудовой ГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **5** |
| Кызыл Чапчак ГББМ | 6,80 | 15,0 | 21,8 | **1** |
| Колмакчы ГББм | 6,80 | 15,0 | 21,8 | **2** |
| Прости ГББМ | 6,80 | 20,0 | 26,8 | **3** |
| гомуми | | | | **286** |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 16 гыйнварындагы
23 номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаиләләрдәге балаларны
тукландыруны оештыру тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдәге балалар өчен кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру максатынан, түбәндәге категорияле укучыларга эшләнгән:

- ятим балалар һәм опекага алынган балалар;
- инвалид балалар;
- Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы гаилә балалары;
- җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган азкеремле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдәге балалар.

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан туклану өчен ата-аналар кертемнәреннән азат итү юлы белән социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга адреслы социаль ярдәм 2017 елга гомуми белем бирү оешмаларының расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Туклану оештырыла:

2.1. шәһәр гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары өчен көненә 30 сум 70 тиен күләмендә:

- җирле бюджет акчалары исәбеннән 23 сум 90 тиен;
- туклануга субсидияләр - 6 сум 80 тиен.

2.2. шәһәр гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучылары өчен көненә 35 сум 70 тиен, шул исәптән:

- җирле бюджет акчалары исәбеннән 28 сум 90 тиен;
- туклануга субсидияләр - 6 сум 80 тиен.

3.Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар аш белән туклandыруны оештыру өчен гомуми белем бирү оешмаларында директор, педагогик коллективтан укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплы һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссия төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

Комиссия уку елы башында һәм алга таба да кирәк булганда:

- тәкъдим ителгән гаризаларны карый һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә;
- азкеремле, тулы булмаган, күпбалалы гаиләләрне һәм аларның торак шартларын тикшерә, аларның матди хәлен, гаиләдәге балалар һәм

иждивенецларның санын билгели, укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә, әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча тикшерү нәтиҗәләре белән беррәттән актта терки:

- категорияләр буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучылар исемлеген раслый;
- сыйныф җитәкчесе яки озынайтылган көн төркеме тәрбиячесе җитәкчелегендә укучылар тарафыннан ашханәгә төркемләп йөрү графигын эшли;
- бирелә торган төшке ашларның билгеләнгән тәртиптә расланган менюга туры килүен тикшерә.

Комиссия хокуклы:

- җитешсезлекләр белән әзерләнгән ризыкларны сатудан төшерергә;
- медицина хезмәткәре белән берлектә китерелә торган азык-төлек продуктларының туры килү-килмәвен тикшерә, үлчәүне тикшереп торырга һ. б.
- тикшерү нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмасы директорыннан җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне таләп итәргә.

4. Сыйныф җитәкчеләре:

- әлеге нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча түләүсез туклану алу өчен ата-аналардан яисә аларны алмаштыручы затлардан гаризалар кабул ителәр;
- гаризаларны алганнан соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;
- сыйныф укучыларының тукрануын категорияләр буенча исәпкә алып баралар;
- укучылар һәм ата-аналар арасында мәктәп укучыларын тулысынча тукландыру кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар;
- барлык сыйныф укучыларының да ашханәгә йөрүен контрольдә тоталар;
- ашханәдә туклану өчен «Мәктәптә туклану» модуле аша түләгәндә, сыйныф укучыларына «Укучы картасы»н куллану буенча аңлаталар, кирәк булганда ярдәм итәләр.

5. Ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

6. Гомуми белем бирү оешмалары директорлары:

6.1.Укучыларны гаиләне тикшерү акты нигезендә категорияләр буенча түләүсез туклану белән тәэмин итү буенча боерыклар чыгара.

6.2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә укучылар исемлеген категорияләр буенча тапшыралар.

7.Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе укучыларны тукландыруны оештыру, азык әзерләү технологиясен үтәү, чыгышын, азык-төлек блогларында санитар нормаларны үтәү мәсьәләләрен гомуми белем бирү оешмаларына чыгып тикшерәләр.

8. Әлеге Нигезләмә шәһәр гомуми белем бирү оешмаларына кагыла.

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаилә
укучыларын тукландыруны оештыру тәртибенә
1 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәре ___мәктәбе _____сыйныфы укучысы
_________________Ф.И. А.ис.
гаиләсен тикшерү
АКТЫ

Түбән Кама шәһәре 20__ елның _________________

Гаилә ______________________________________________________________________
(тулы булмаган, күпбалалы, социаль куркыныч хәлдә булган гаилә)
түбәндәге адрес буенча фатирда (йортта) яши:
_____________________________________________________________________________
(бүлмәләр саны, мәйданы, уңайлылык, коммуналь, тулай торак, аренда)
_____________________________________________________________________________

Гаиләдәге укучылар саны ____, гаиләдә иждевенецлар саны _____.
Гаиләнең матди хәл ________________________________________________________.
(яхшы, уртача, уртадан түбән)
Гаилә әгъзасына җыелма керем тәшкил итә _____ сум (ата-аналарның гаризасы буенча).
Ата-аналарның эш урыны, вазыйфасы, уртача эш хакы:
_____________________________________________________________________________.
Өстәмә мәгълүмат: _________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.
Гаиләнең торак шартларын һәм матди хәлен тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия карар кабул итә:
_________сыйныф укучысы ___________________________________________
(Ф.И.А.ис.)
өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ (мохтаҗ түгел).
(кирәклесен билгеләргә)

Комиссия рәисе: __________________________ ______________________
(имза, дата) (Ф.И.А. ис.)
Комиссия әгъзалары: __________________________ ______________________
(имза, дата) (Ф.И.А. ис.)
Сыйныф җитәкчесе: __________________________ ______________________
(имза, дата) (Ф.И.А. ис.)

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаилә
укучыларын тукландыруны оештыру тәртибенә
2 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәре ___мәктәбе укучыларының
туклануны оештыру буенча комиссиясенә

______________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. ис.)

____________________________________
(адресы)

гариза.

Улым (кызым, опекага алынган бала)
_________________________________________________________________________________,
(Ф.И.А. ис.)
_____ сыйныф укучысын түләүсез туклануга куюыгызны сорыйм.

Гаилә әгъзасына җан башына уртача керем ________________ сум тәшкил итә.

Өстәмә мәгълүмат: _____________________________________
__________________________________________________________________.

Гаилә кеременең күләмен раслаучы документлар кушымта итеп бирелә.

_____________________
(Дата, имза)

--------------------------------

Гаризага кушымта итеп бирелә:

1. Гаилә составы турында белешмә.
2. Эш урыныннан хезмәт хакы турында белешмә (соңгы 6 ай өчен).
3. Пенсия, пособиеләр күләме турында белешмә.
4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгеннән белешмә (эшләмәүчеләр өчен).
5. Күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе (булганда).
6. Опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә, яисә балигъ булмаганнарны опекага алу турында күрсәтмә күчермәсе.
7. Инвалид балалар өчен МСЭ медицина белешмәсе күчермәсе.
8. Өйләнешү яки аерылышу турында таныклык күчермәсе.
9. Алиментлар алу турында белешмә (булганда).
10. Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыклыгы күчермәсе.